МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.12.2024 Казан ш. № 02-121

Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләрне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләрне (алга таба – Күрсәтмәләр) (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Күрсәтмәләрнең, 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан башлап, Татарстан Республикасы бюджетын һәм Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә кулланылуын билгеләргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры М.Д.Фәйзрахмановка йөкләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
26.12.2024 ел,
№ 02-121

боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләр

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында бу күрсәтмәләр (алга таба – Күрсәтмәләр), Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына караган өлешендә Татарстан Республикасында бюджет процессында барлык катнашучылар тарафыннан Россия Федерациясе бюджет классификациясен (алга таба – бюджет классификациясе) куллану тәртибен билгели.

Керемнәрнең, чыгымнарның һәм бюджетлар дефицитларын финанслау чыганакларының бюджет классификациясе – ул Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары өчен бердәм булып тора, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә кулланыла.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты средстволарының баш бүлүчесе коды өч разрядтан тора һәм 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 0 саннарын кулланып булдырыла.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты средстволарының баш бүлүчесе коды Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы составында расланган тиешле бюджетлар средстволарын баш бүлүчеләр исемлеге нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты средстволарын баш бүлүчеләрнең кодлары бу Күрсәтмәләргә № 1 кушымтада бирелгән.

Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының максатчан статьялары Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләренең Татарстан Республикасы Дәүләт программаларына, аларның кече программаларына, Татарстан

Республикасы дәүләт органнары эшчәнлегенең программаларга кертелмәгән юнәлешләренә һәм чараларына бәйләнешне тәэмин итә.

Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты чыгымнары әлеге бюджетның бюджет ассигнованиеләренең эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды идарә органы эшчәнлегенең (функцияләренә) төп юнәлешләренә бәйләнешен тәэмин итә.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты чыгымнарының максатчан статьясы коды ун разрядтан (бюджетлар чыгымнары классификациясе кодының 8-17 разрядлары) тора.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты чыгымнарының максатчан статьясы коды структурасы бу Күрсәтмәләрнең нигезләмәләреннән чыгып билгеләнә һәм түбәндәге өлешләрдән тора:

Татарстан Республикасы дәүләт программалары, Татарстан Республикасы дәүләт органнарының, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды органының программаларга кертелмәгән юнәлешләре буенча бюджет ассигнованиеләрен кодлаштыру өчен билгеләнгән, эшчәнлекнең программага кертелгән (программага кертелмәгән) юнәлеше коды (бюджетлар чыгымнары классификациясе кодының 8-9 разрядлары);

Татарстан Республикасы дәүләт программаларының структур элементлары типлары, Татарстан Республикасы дәүләт органнарының, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды органы эшчәнлегенең программага кертелмәгән элементлары буенча билгеләнгән структур элементның (программага кертелмәгән эшчәнлек юнәлеше элементы) тибының коды (бюджетлар чыгымнары классификациясе кодының 10 разряды);

федераль проектлар, төбәк проектлар, Татарстан Республикасы дәүләт программалары кысаларында процесс чаралары комплекслары, шулай ук эшчәнлекнең программага кертелмәгән юнәлешләре кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән аерым чаралар буенча бюджет ассигнованиеләрен кодлаштыру өчен билгеләнгән структур элемент коды (бюджетлар чыгымнары классификациясе кодының 11-12 разрядлары);

аерым чараларны тәгаенләштерүче (кирәк булганда) средстволар чыгымнары юнәлешләрен кодлаштыру өчен билгеләнгән чыгымнар юнәлеше коды (бюджетлар чыгымнары классификациясе кодының 13-17 разрядлары).

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнарының максатчан статьяларына хәреф-сан рәтен кулланып төзелгән уникаль кодлар бирелә: 0, 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, А, Б, В, Г, Д, Е, Ж, и, К, Л, м, н, П, Р, С, Т, У, Ф, Ц, Ч, Ш, Щ, Э, Ю, Я, A, B, C, D, E, F, G, H, I, J, K, L, M, N, P, Q, R, S, T, U, V, W, Y, Z.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнарының максатчан статьялары исемнәре Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан

билгеләнә һәм бюджет ассигнованиеләрен түбәндәгеләрне гамәлгә ашыруга җибәрүне күрсәтә:

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлегенең программага кертелмәгән юнәлешләрен, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды идарә органы эшчәнлегенең программага кертелмәгән юнәлешләрен;

Татарстан Республикасы дәүләт программаларының структур элементлары, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондының идарә органы эшчәнлегенең программага кертелмәгән юнәлешләре элементлары типларын;

федераль проектлар, төбәк проектларын, Татарстан Республикасы дәүләт программалары кысаларындагы процесс чаралары комплексларын, шулай ук эшчәнлекнең программага кертелмәгән юнәлешләре кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән аерым чараларны;

чыгымнар юнәлешләрен.

30000 – 39990 һәм 50000 – 59990, шулай ук R0000 – R9990, L0000 – L9990, S0000 – S9990 күрсәткечләрен үз эченә алган чыгым юнәлешләре кодлары, әгәр әлеге Күрсәтмәләр белән башкасы билгеләнмәгән булса, кулланыла:

30000 – 39990 һәм 50000 – 59990 юнәлешләре кодлары финанс белән тәэмин итү чыганагы булып федераль бюджеттан (Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларыннан) бирелә торган субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар торган Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты чыгымнарын чагылдыру өчен кулланыла. Әлеге чыгымнарны чагылдыру «Россия Федерациясе бюджет классификациясе кодларын, аларның структурасын һәм билгеләнеше принципларын булдыру һәм куллану тәртибе турында» 24 май, 2022 ел, № 82н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы белән раслаган Россия Федерациясе бюджет классификациясе кодларын, аларның структурасын һәм билгеләнеше принципларын булдыру һәм куллану нигезендә хәл ителә;

R0000 – R9990 юнәлешләре коды Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын (илкүләм проектлар составына керүче федераль проектларны тормышка ашыру буенча тиешле нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән төбәк проектларны гамәлгә ашыру чыгымнарыннан тыш), шул исәптән, җирле бюджетларга финанслашу максатында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджетка субсидияләр һәм башка бюджетара трансфертлар бирелә торган җирле бюджетларга бюджетара трансфертлар бирүгә чыгымнарны чагылдыру өчен кулланыла;

R0000 – R9990 юнәлешләре коды, үзләрен финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр бирелә торган җирле бюджетлар чыгымнарын (илкүләм проектлар составына керүче федераль проектларны тормышка ашыру буенча тиешле нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән төбәк проектларын тормышка ашыру чыгымнарыннан тыш) чагылдыру өчен кулланыла, аларны финанслашу максатында (шул исәптән тулы күләмендә)

Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр һәм башка бюджетара трансфертлар бирелә.

L0000 – L9990 юнәлешләре кодлары, үзләрен финанслашу максатыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр һәм башка бюджетара субсидияләр, үзләрен финанслашу (шул исәптән тулы күләмдә) максатыннан Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр һәм башка бюджетара трансфертлар бирелә торган җирле бюджетлар чыгымнарын (илкүләм проектлар составына керүче федераль проектларны тормышка ашыру буенча тиешле нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән төбәк проектларын тормышка ашыру чыгымнарыннан тыш) чагылдыру өчен кулланыла;

S0000 – S9990 юнәлешләре кодлары үзләрен финанслашу (шул исәптән тулы күләмдә) максатыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субсидияләр һәм башка бюджетара трансфертлар бирелә торган, җирле бюджет средстволарын алучының акчалата йөкләмәләрен түләүдә муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен финанслашу буенча билгеләнгән күрсәткечкә туры килә торган өлештә җирле бюджетка субсидияләр һәм башка бюджетара трансфертлар күчерүдә федераль бюджеттан һәм Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларыннан финанслашылмый торган җирле бюджетлар чыгымнарын чагылдыру өчен кулланыла.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар чыгымнары юнәлешләреннән торган чыгымнарның максатчан статьялары кодларын, R0000 – R9990, L0000 – L9990, S0000 – S9990, формалаштыруда чыгымнар юнәлешләренең икенче-дүртенче разрядлары дәрәҗәсендә Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджетлар) чыгымнары кодларының бюджетара трансферт бирүче Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты чыгымнарының юнәлешләре кодларына бәйләнеше тәэмин ителә.

Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр торган Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты һәм җирле бюджетлар чыгымнарын чагылдыру чыгымнар юнәлеше кодында беренче-дүртенче разрядлардан торучы, югарыда күрсәтелгән бюджетара трансфертлар бирүдә федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла торган федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары юнәлешләре кодының беренче-дүртенче разрядларына тәңгәл килүче бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары буенча хәл ителә. Шул ук вакытта күрсәтелгән бюджет чыгымнары юнәлеше атамасында тиешле бюджет чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып торучы федераль трансферт һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансферт күрсәтелми.

Илкүләм проектлар составына керүче федераль проектларны тормышка ашыру буенча тиешле нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән төбәк проектларын тормышка ашыру чыгымнарының максатчан статьялары буенча Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты һәм җирле бюджетлар чыгымнарын чагылдыру, «Россия Федерациясе бюджет классификациясе кодларын, аларның структурасын һәм билгеләнеше принципларын булдыру һәм куллану тәртибе турында» 24 май,

2022 ел, № 82н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы нигезендә билгеләнгән кодларның күрсәткечләре нигезендә, чыгымнарның максатчан статьясы кодының
(00 0 XX 00000) 4-5 разряды буенча хәл ителә.

Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып максатчан билгеләнешкә ия булган Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар торган җирле бюджетлар чыгымнарын чагылдыру үзләре буенча югарыда күрсәтеп үтелгән бюджетара трансфертлар бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының тиешле юнәлешләре кодына тәңгәл булган чыгымнар юнәлешләре кодларыннан (бюджетлар чыгымнары кодының 13-17 разрядлары) җирле бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары буенча хәл ителә.

Финанс елы эчендә бюджет чыгымнарының максатчан статьясы атамасына һәм (яки) кодына үзгәрешләр кертү рөхсәт ителми, финанс елы дәвамында әлеге бюджетлар чыгымнарының максатчан статьясы буенча тиешле бюджетның касса чыгымнары хәл ителмәгәндә, шулай ук бу Күрсәтмәләр нигезендә башкача билгеләнмәгәндә.

Түбәндәге очракларда финанс елы дәвамында максатчан статья атамасына һәм (яки) кодына үзгәрешләр кертелергә мөмкин:

- юридик зат атамасын Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 4 бүлегендәге нигезләмәләргә туры китерүгә бәйле рәвештә, максатчан статья атамасындагы юридик зат атамасын үзгәртү ягыннан;

- финанслашу (финанс белән тәэмин итү) максатында Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджетына финанс елы дәвамында федераль бюджеттан бюджетара трансфертлар бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты чыгымнарын чагылдыру өчен максатчан статья атамасын һәм (яки) кодын үзгәртү ягыннан;

– тиешле чыгым йөкләмәләрен билгеләүче Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, шул исәптән тиешле чыгым йөкләмәләрен билгеләүче норматив-хокукый актлар үзгәртелүгә бәйле рәвештә, максатчан статья атамасын үзгәртү ягыннан;

- илкүләм проектлар составына керүче федераль, төбәк проектларын тормышка ашыру нәтиҗәләренә үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, илкүләм проектлар составына керүче федераль, төбәк проектларын тормышка ашыру нәтиҗәләрен чагылдыручы чыгымнар юнәлешләре атамаларын үзгәртү ягыннан.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты чыгымнарының максатчан статьялары исемлеге бу Күрсәтмәләргә № 2 кушымтада китерелгән.

2025 елга бюджетлардан башлап, кулланугa тәкъдим ителә торган җирле бюджетлар чыгымнарының аерым максатчан статьялары исемлеге бу Күрсәтмәләргә № 3 кушымтада китерелгән.

Мәгълүматлаштыру системалары һәм мәгълүмати-коммуникацион инфраструктура ягыннан, мәгълүматларшытру чараларын тормышка ашыруга

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты чыгымнары «Мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсендә товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу» 242 чыгымнар төре буенча чагылдырыла.

## 2. Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты чыгымнары исемлеге һәм аларны тиешле максатчан статьяларга кертү кагыйдәләре

### 2.1. «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасы

«Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасының максатчан статьялары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

01 0 00 00000 Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасы»

Әлеге максатчан статья буенча «Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» 30.05.2023 ел, № 655 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнгән «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыруга түбәндәге юнәлешләр буенча хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

01 2 00 00000 Федераль (төбәк) проектлар

01 2 02 00000 «Киңәйтелгән неоноталь скринингны тәэмин итү» төбәк проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча төбәк проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- R3850 Яңа туган балаларны тумыштан һәм (яки) нәселдән килүче авырулар буенча массакүләм тикшерү (киңәйтелгән неоноталь скрининг) чараларын тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча яңа туган балаларны тумыштан һәм (яки) нәселдән килүче авырулар буенча массакүләм тикшерү (киңәйтелгән неоноталь скрининг) чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Яңа туган балаларны тумыштан һәм

(яки) нәселдән килүче авырулар буенча массакүләм тикшерү (киңәйтелгән неонаталь скрининг) чараларын тормышка ашыруда килеп чыгучы Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен фирнанслашу максатыннан чыгып, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25385 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

01 2 03 00000
«Беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү» төбәк проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча төбәк проектын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары, шул исәптән:

- 97040 Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация үткәрүне оештыру чаралары

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация үткәрүне оештыру чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 97090 Сәламәтлек саклау системасы кысаларында үткәрелә торган чаралар

- 97091 Социаль өлкә хезмәткәрләренә мәҗбүри башлангыч, билгеле бер вакыт аралыкларында медицина тикшерүләре (тикшеренүләре) уздыруны оештыру

01 2 08 00000 Төбәк проекты
«Гражданнарны сәламәт яшәү рәвешен алып баруга этәргеч бирү системасын формалаштыру, сәламәт туклануны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны кертеп»

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча төбәк проектын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 17020 Хәмер куллануны һәм тәмәке тартуны киметүне кертеп, Россия Федерациясендә яшәүчеләрнең сәламәт яшәү рәвешен булдыруга юнәлдерелгән гамәлләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча, хәмер һәм тәмәке куллануны киметүне кертеп, Россия Федерациясенә яшәүчеләрнең сәламәт яшәү рәвешен булдыруга юнәлдерелгән чараларны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

01 2 0К 00000 «Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү»
төбәк проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 72310 Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкендәге социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт.

01 2 10 00000 «Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү» төбәк проекты

Әлеге максатчан маддә буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча төбәк проектын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары, шул исәптән:

- 17000 Табибларга – яшь белгечләргә социаль ярдәм чараларын финанс белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча табибларга – яшь белгечләргә социаль ярдәм чараларын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 18000 Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алган белгеч табибларга, клиник-лаборатор диагностика табибларына дәүләт ярдәме чараларын финанс белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алган белгеч табибларга, клиник-лаборатор диагностика табибларына дәүләт ярдәме чараларын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 97090 Сәламәтлек саклау системасы кысаларында үткәрелә торган чаралар

- 97092 Һөнәрнең абруен күтәрү өчен медицина хезмәткәрләре конкурсын үткәрү чаралары

01 2 Д1 00000 «Россия Федерациясендә сәламәтлек саклауның беренчел буынын модернизацияләү» федераль проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча федераль проектны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 53650 Сәламәтлек саклауның беренчел буынын модернизацияләү буенча төбәк проектын гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча сәламәтлек саклауның беренчел буынын модернизацияләүнең төбәк проектын гамәлгә ашыруга федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Сәламәтлек саклауның беренчел буынын модернизацияләүнең төбәк проектларын гамәлгә ашыруга Россия

Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25365 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

01 2 Д2 00000 «Йөрәк-кан тамырларына каршы көрәшү»
федераль проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 55860 Диспансер күзәтүендә торучы, сәламәтлегенә югары дәрәҗәдә хәтәр яный торган пациентларда йөрәк-кан тамырлары авырулары һәм йөрәк-кан тамырлары өзлегүләрен профилактикалауны тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча, диспансер күзәтүендә торучы, сәламәтлегенә югары дәрәҗәдә хәтәр яный торган пациентларда йөрәк-кан тамырлары авырулары һәм йөрәк-кан тамырлары өзлегүләрен профилактикалауны тәэмин итүгә федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Диспансер күзәтүендә торучы, сәламәтлегенә югары дәрәҗәдә хәтәр яный торган пациентларда йөрәк-кан тамырлары авырулары һәм йөрәк-кан тамырлары өзлегүләрен профилактикалауны тәэмин итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25586 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

01 2 Д4 00000 «Шикәр чиренә каршы көрәш» федераль проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча федераль проектны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 51070 1 типтагы шикәр чиреннән интегүче 2-17 яшьлек балаларны кандагы глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү чараларын тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча 1 типтагы шикәр чиреннән интегүче 2-17 яшьлек балаларны кандагы глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка субсидияләр» 000 2 02 29999 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

- 51520 Шикәр чиреннән интегүче хатын-кызларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча шикәр чиреннән интегүче хатын-кызларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка субсидияләр» 000 2 02 29999 02 0000 150 керем төрләре коды буенча чагылдырыла.

- 51580 Углевод алмашы бозылган һәм шикәр чиреннән интегүче авыруларга медицина ярдәме күрсәтә торган төбәк, районара (район) үзәкләрне җиһазлауга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча углевод алмашы бозылган һәм шикәр чиреннән интегүче авыруларга медицина ярдәме күрсәтүче төбәк, районара (район) үзәкләрне җиһазландыруга федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка субсидияләр» 000 2 02 29999 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

01 2 Д5 00000
Федераль проект «С гепатиты белән көрәшү һәм
әлеге авыруның таралу куркынычын киметү» федеральный проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча федераль проектны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 52140 «Вируслы хроник С гепатиты» диагнозы белән диспансер күзәтүендә булган затларны амбулатор шартларда вируска каршы дару препаратлары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Вируслы хроник С гепатиты» диагнозы белән диспансер күзәтүендә булган затларны амбулатор шартларда вируска каршы дару препаратлары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Вируслы хроник С гепатиты» диагнозы белән диспансер күзәтүендә булган затларны амбулатор шартларда вируска каршы дару препаратлары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруда килеп чыгучы Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу

максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25214 02 0000 150 керемнәртөре коды буенча чагылдырыла.

01 2 Д6 00000 «Ашыгыч медицина ярдәмен камилләштерү»
федераль проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча федераль проектны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 55540 Медицина ярдәме күрсәтү максатларында авиация эшләрен сатып алуны тәэмин итүгә финанслашу чыгымнары

Бу юнәлеш буенча чыгымнар чагылдырыла:

- медицина ярдәме күрсәтү максатларында авиация эшләрен сатып алуны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирүгә федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Медицина ярдәме күрсәтү максатларында авиация эшләрен сатып алуны тәэмин итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25554 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

- медицина ярдәме күрсәтү максатларында авиация эшләрен сатып алуны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары.

Әлеге максатларга бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына кире кайтарылмый торган башка кертемнәр» 000 2 02 90029 09 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

01 2 Д7 00000 «Сәламәтлекне торгызу өчен оптималь
медицина реабилитациясе» федераль проекты

Әлеге максатчан маддә буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча федераль проектны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 57520 Үз структурасында медицина реабилитациясе буенча медицина ярдәме күрсәтүче бүлекчәләре булган медицина оешмаларын медицина әйберләре белән җиһазлау (тулыландыру һәм (яисә) яңадан җиһазлау) гамәлләрен гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча үз структурасында медицина реабилитациясе буенча медицина ярдәме күрсәтүче бүлекчәләре булган медицина оешмаларын медицина әйберләре белән тәэмин итү (тулыландыру һәм (яисә) яңадан җиһазлау) чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджет субсидияләре һәм

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәрен классификациясенең «Үз структурасында медицина реабилитациясе буенча медицина ярдәме күрсәтүче бүлекчәләре булган медицина оешмаларын медицина әйберләре белән тәэмин итүгә (тулыландыруга һәм (яисә) яңадан җиһазландыруга) Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25752 02 0000 150» керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

01 2 ДА 00000 «Һәркем өчен сәламәтлек» федераль проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча федераль проектны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 55460 Район һәм район үзәк хастаханәләрендә, шул исәптән еракта урнашкан торак пунктларда медицина профилактикасы бүлекчәләре (кабинетлары) базасында өлкәннәр өчен сәламәтлек үзәкләрен оештыруга, шулай ук йогышлы булмаган хроник авырулар пәйда булу куркынычын ачыклау һәм куркыныч факторларын коррекцияләү өчен җиһазлар белән тәэмин итүгә (җиһазландыруга) финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча район үзәк хастаханәләрендә һәм район хастаханәләрендә, шул исәптән еракта урнашкан торак пунктларда медицина профилактикасы бүлекләре (кабинетлары) базасында өлкәннәр өчен сәламәтлек үзәкләрен оештыруга, шулай ук йогышлы булмаган хроник авырулар куркынычы факторларын ачыклау һәм коррекцияләү өчен җайланмалар белән җиһазландыруга (тулыландыруга) федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка субсидияләр» 000 2 02 29999 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

01 2 ЯЗ 00000
«Ана һәм баланы саклау» федераль проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча федераль проектны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 53140 Хатын-кызларга, шул исәптән авыл җирендә, шәһәр тибындагы бистәләрдә һәм кече шәһәрләрдә яшәүче хатын-кызларга медицина ярдәме күрсәтү өчен, хатын-кызлар консультацияләре булдыруга, шул исәптән башка оешмалар составында, финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча хатын-кызларга, шул исәптән авыл җирендә, шәһәр тибындагы бистәләрдә һәм кече шәһәрләрдә яшәүче хатын-кызларга медицина ярдәме күрсәтү өчен, хатын-кызлар консультацияләре булдыруга, шул исәптән башка оешмалар составында, федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка субсидияләр» 000 2 02 29999 02 0000 150 керем төрләре коды буенча чагылдырыла.

- 53160 Перинаталь үзәкләрне һәм бала тудыру йортларын (бүлекләрне), шул исәптән башка оешмалар составындагы, медицина әйберләре белән җиһазлауга (җиһазландыруга һәм (яисә) яңадан җиһазландыруга) финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча перинаталь үзәкләрне һәм бала тудыру йортларын (бүлекләрен), шул исәптән башка оешмалар составында, медицина әйберләре белән тәэмин итүгә (тулыландыруга һәм (яисә) яңадан җиһазландыруга) федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка субсидияләр» 000 2 02 29999 02 0000 150 керем төрләре коды буенча чагылдырыла.

### 01 4 00 00000 Процесс чаралары комплекслары

### 01 4 01 00000 «Ана һәм бала сәламәтлеген саклау» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 60730 Неонаталь һәм аудиологик скрининг өчен җиһазлар һәм куллану материаллары сатып алу гамәлләре

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча неонаталь һәм аудиологик скрининг өчен җиһазлар һәм чыгым материаллары сатып алу чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 60790 Пренаталь (бала тудырганчы) диагностика чаралары

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча пренаталь (бала тудырганчы) диагностика чараларын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 97100 Ведомство буйсынуындагы сәламәтлек саклау учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча ведомство буйсынуындагы сәламәтлек саклау учреждениеләрен тотуга һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

01 4 02 00000 «Татарстан Республикасы медицина оешмаларының матди-техник базасын ныгыту» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чаглдырыла, шул исәптән:

- 97050 Сәламәтлек саклау учреждениеләрен матди-техник тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча сәламәтлек саклау учреждениеләрен матди-техник тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

01 4 03 00000 «Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүне һәм һәлакәтләр медицинасы хезмәте эшчәнлеген камилләштерү» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан маддә буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 97160 Ашыгыч медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча ашыгыч медицина ярдәме станцияләрен һәм бүлекчәләрен тотуга һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

01 4 04 00000 «Татарстан Республикасында органнар донорлыгын һәм аларны күчереп утыртуны оештыру» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары, шул исәптән:

- R4760 Трансплантацияләү (күчереп утырту) максатларында кеше органнары донорлыгына бәйле медицина эшчәнлеген федераль бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча трансплантацияләү (күчереп утырту) максатларында кеше органнары донорлыгына бәйле медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагыла.

Әлеге максатларга бүтән бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Трансплантацияләү (күчереп утырту) максатларында кеше органнары донорлыгына бәйле медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

01 4 05 00000 «Аерым категориядәге гражданнарны дару препаратлары белән тәэмин итү» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары, шул исәптән:

- 01010 Эпидемик күрсәткечләр буенча профилактик прививкалар ясау өчен вакциналарны үзәкләштерелгән сатып алулар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча эпидемик күрсәткечләр буенча профилактик прививкалар ясау өчен вакциналарны үзәкләштерелгән сатып алуларга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 02110 Йогышлы авырулар чыганакларында, шулай ук йогышлы авырулар килеп чыгу һәм таралу өчен шартлар булган һәм сакланып калган территорияләрдә һәм бина-бүлмәләрдә лаборатор тикшеренү ысулларын кулланып дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация, санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар үткәрү буенча чараларны хәл кылуны оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча йогышлы авырулар чыганакларында, шулай ук йогышлы авырулар килеп чыгу һәм таралу өчен шартлар булган һәм сакланып калган территорияләрдә һәм бина-бүлмәләрдә лаборатор тикшеренү ысулларын кулланып дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация, санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар үткәрү буенча чараларны хәл кылуны оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга җирле бюджетларга субвенцияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең җирле бюджетларга керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектларына тапшырыла торган вәкаләтләрне үтәүгә җирле бюджетларга субвенцияләр» 000 2 02 30024 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

Шулай ук чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр хисабына хәл ителә торган җирле бюджетлар чыгымнары чагылдырыла.

- 51610 Федераль бюджет средстволары хисабына, дарулар белән тәэмин итү өлкәсендәге вәкаләтләрне тормышка ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча дарулар белән тәэмин итү өлкәсендәге вәкаләтләрне тормышка ашыруга федераль бюджеттан башка бюджетара

трансфертлар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Дарулар белән тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45161 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

- 54600 Федераль бюджет средстволары хисабына, дару препаратларына рецептлар буенча медицина максатында куллануга дару препаратлары белән тәэмин итү, медицина әйберләренә рецептлар буенча медицина әйберләре белән тәэмин итү, шулай ук инвалид балалар өчен сихәтле махсус ризыклар белән тәэмин итү буенча гражданнарның аерым категорияләренә социаль хезмәт күрсәтү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча дару препаратларына рецептлар буенча медицина максатында куллануга дару препаратлары белән тәэмин итү, медицина әйберләренә рецептлар буенча медицина әйберләре белән тәэмин итү, шулай ук инвалид балалар өчен сихәтле махсус ризыклар белән тәэмин итү буенча гражданнарның аерым категорияләренә социаль хезмәт күрсәтүгә федераль бюджеттан субвенцияләр хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Дару препаратларына рецептлар буенча медицина максатында куллануга дару препаратлары белән тәэмин итү, медицина әйберләренә рецептлар буенча медицина әйберләре белән тәэмин итү, шулай ук инвалид балалар өчен сихәтле махсус ризыклар белән тәэмин итү буенча гражданнарның аерым категорияләренә социаль хезмәт күрсәтүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субвенцияләр» 000 2 02 35460 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

- 77010 Дарулар белән эш итү өлкәсендә килеп чыгучы мөнәсәбәтләрне билгеләнгән тәртиптә җайга салу

- R2160 Гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, лимфоид, канъясагыч һәм шуларга тиңдәш тукымаларның яман шешләре, таркау склероз, гемолитик-уремик синдром, системалы башлангычлы үсмерләр артриты, I, II һәм VI типтагы мукополисахаридоз, анықланмаган апластик анемия, II (фибриноген), VII (Лабиль), X (Стюарт – Прауэр) факторларының нәселдән килгән дефициты авыруларыннан интегүчеләрне, шулай ук органнар һәм (яисә) тукымалар трансплантациясеннән соң дәвалау өчен билгеләнгән дару препаратлары белән затларны тәэмин итүгә бәйле оештыру чараларын гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, лимфоид, канъясагыч һәм шуларга тиңдәш тукымаларның яман шешләре, таркау склероз, гемолитик-уремик синдром, системалы башлангычлы үсмерләр артриты, I, II һәм VI типтагы мукополисахаридоз, анықланмаган апластик анемия, II (фибриноген), VII (Лабиль), X (Стюарт – Прауэр) факторларының нәселдән килгән дефициты авыруларыннан интегүчеләрне, шулай

ук органнар һәм (яисә) тукымалар трансплантациясеннән соң дәвалау өчен билгеләнгән дару препаратлары белән затларны тәэмин итүгә бәйле оештыру чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла,

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, лимфоид, канъясагыч һәм шуларга тиңдәш тукымаларның яман шешләре, таркау склероз, гемолитик-уремик синдром, системалы башлангычлы үсмерләр артриты, I, II һәм VI типтагы мукополисахаридоз, анықланмаган апластик анемия, II (фибриноген), VII (Лабиль), X (Стюарт – Прауэр) факторларының нәселдән килгән дефициты авыруларыннан интегүчеләрне, шулай ук органнар һәм (яисә) тукымалар трансплантациясеннән соң дәвалау өчен билгеләнгән дару препаратлары белән затларны тәэмин итүгә бәйле оештыру чараларын гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25216 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

- R4680 Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче хезмәткә сәләтле яшьтән өлкәнрәк булган сәламәтлегенә куркыныч яный торган төркемнәргә керүче гражданнарга пневмококк инфекциясенә каршы вакцинация үткәрүгә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче хезмәткә сәләтле яшьтән өлкәнрәк булган сәламәтлегенә куркыныч яный торган төркемнәргә керүче гражданнарга пневмококк инфекциясенә каршы вакцинация үткәрүгә федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче хезмәткә сәләтле яшьтән өлкәнрәк булган сәламәтлегенә куркыныч яный торган төркемнәргә керүче гражданнарга пневмококк инфекциясенә каршы вакцинация үткәрүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25468 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

01 4 06 00000 «Кан салу хезмәтен үстерү»
процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан маддә буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 97200 Кан салу үзәкләре. станцияләре һәм бүлекләре

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча донор канын һәм аның компонентларын әзерләүне, эшкәртүне, транспортировкалауны һәм саклауны гамәлгә ашыручы сәламәтлек саклау учреждениеләрен (йә аларның структур бүлекчәләрен) тотуга һәм

аларның эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

01 4 07 00000 «Профилактика, диагностика, дәвалау һәм реабилитацияләү ысулларын клиник апробацияләү кысаларында күрсәтелә торган югары технологияле медицина ярдәме һәм медицина ярдәме» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 05180 Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү

- R4020 Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә финанслашыла торган чыгымнар

Бу юнәлеш буенча чыгымнар чагылдырылп:

- Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирүгә федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәткәндә барлыкка килә торган чыгымнарны финанслашу максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» керем төрләре коды буенча чагылдырыла;

- Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары.

Әлеге максатларга бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына кире кайтарылмый торган башка кертемнәр» 000 2 02 90029 09 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

01 4 08 00000 «Социаль әһәмиятле авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 03820 Кеше иммунодефициты вирусларын, шул исәптән B һәм (яисә) C гепатитлары вирусларын йоктырган затларны ачыклау һәм дәвалауны мониторинглау өчен диагностика чаралары сатып алуларны финанс белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча кеше иммунодефициты вирусларын, шул исәптән B һәм (яисә) C гепатитлары вирусларын ачыклау һәм дәвалауны мониторинглау өчен диагностика чараларын сатып алуларны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 97030 Сәламәтлек саклау өлкәсендә башка чаралар

- R2020 Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыруга башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» керем төрләре коды буенча чагылдырыла.

01 4 09 00000 «Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» керем төрләре коды буенча чагыла.

- 02020 Паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә, шул исәптән балаларга чыгымнар

Әлеге юнәлеш буенча паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә, шул исәптән медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша башлыча бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге юнәлеш буенча Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондына паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә, шул исәптән медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер

каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга бюджетара трансфертлар бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына кире кайтарылмый торган башка кертемнәр» 000 2 02 90029 09 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

Шулай ук чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондының паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә, шул исәптән балаларга да, чыгымнары чагылыш таба.

- R2010 Паллиатив медицина ярдәмен үстерү максатларында финанслашу чыгымнары

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә» проектын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 51210 Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең имин һәм уңайлы шартларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән программаларны финанс белән тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең имин һәм уңайлы шартларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән программаларны финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең имин һәм уңайлы шартларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән программаларны финанс белән тәэмин итү кысаларында дәүләт (муниципаль) милке объектларына капитал салуларны финанслашуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 27121 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла

- 51630 Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыруга федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25163 02 0000 150 керем төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

03 4 00 00000 Процесс чаралары комплекслары

03 4 01 00000 «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан маддә буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 05410 Социаль сәясәт өлкәсендәге чаралар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча социаль сәясәт өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05480 Торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә халыкка социаль ярдәм чараларын тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә халыкка социаль ярдәм чараларын тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05520 Халыкка социаль ярдәм чараларын тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча халыкка социаль ярдәм чараларын тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 06400 Балаларны тукландыру өчен сөт белән тәэмин итүче авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә алынмаган керемнәрне каплауга субсидия

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча балаларны тукландыру өчен сөт белән тәэмин итүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмаган керемнәрен каплауга субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 13140 Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алуга бәйле рәвештә гражданнарга бер мәртәбә өстәмә акчалата түләү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алуга бәйле рәвештә гражданнарга бер мәртәбә өстәмә акчалата түләүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

-23110 Гаиләләргә тәрбиягә тапшырылган ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны матди карап торуга айлык акчалата түләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча гаиләләргә тәрбиягә тапшырылган ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны матди карап торуга җирле бюджетларга айлык акчалата түләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең җирле бюджетларга керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектларының тапшырыла торган вәкаләтләрен үтәүгә җирле бюджетларга субвенцияләр» 000 2 02 30024 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

Шулай ук чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча җирле бюджетларның Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган әлеге максатларга чыгымнары чагылдырыла.

- 23120 Үз вазыйфаларын түләүле башкаручы опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләүне билгеләү һәм түләү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча җирле бюджетларга үз вазыйфаларын түләүле башкаручы опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләүне билгеләү һәм түләү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең җирле бюджетларга керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектларының тапшырыла торган вәкаләтләрен үтәүгә җирле бюджетларга субвенцияләр» 000 2 02 30024 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

Шулай ук чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча җирле бюджетларның Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган әлеге максатларга чыгымнары чагылдырыла.

-23130 Опекага (попечительлеккә) тапшырылган ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны матди карап торуга айлык акчалата түләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча җирле бюджетларга ятим балаларны һәм опекага (попечительлеккә) тапшырылган ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны матди карап торуга айлык акчалата түләү билгеләү һәм түләү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең җирле бюджетларга керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектларының тапшырыла торган вәкаләтләрен үтәүгә җирле бюджетларга субвенцияләр» 000 2 02 30024 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагыла.

Шулай ук чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча җирле бюджетларның Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган әлеге максатларга чыгымнары чагылдырыла.

- 25330 Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга җирле бюджетларга субвенцияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең җирле бюджетларга керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектларының тапшырыла торган вәкаләтләрен үтәүгә җирле бюджетларга субвенцияләр» 000 2 02 30024 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагыла.

Шулай ук чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча җирле бюджетларның Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган әлеге максатларга чыгымнары чагылдырыла.

- 59400 Россия Федерациясе субъектлары арасында, шулай ук Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегендә катнашучы дәүләтләр территорияләре чикләрендә гаиләләреннән, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалардан, мәгариф оешмаларыннан һәм башка оешмалардан рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны йөртүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен федераль бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 3 пункты нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган Россия Федерациясе субъектлары арасында, шулай ук Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегендә катнашучы дәүләтләр территорияләре чикләрендә гаиләләреннән, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалардан, мәгариф оешмаларыннан һәм башка оешмалардан рөхсәтсез киткән балигъ булмаганнарны йөртүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары

бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына бердәм субвенция» 000 2 02 35900 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

- 60830 Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән һәм 23 яшькә җиткән затларга милеккә яисә торак урын сатып алуга бирелгән кредитны (заемны) тулысынча түләп бетерү өчен заем алучының йөкләмәсен ипотека белән тәэмин ителгән килешү буенча төзекләндерелгән торак урын сатып алуга түләүләр бирү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән һәм 23 яшькә җиткән затларга милеккә яисә торак урын сатып алуга бирелгән кредитны (заемны) тулысынча түләп бетерү өчен заем алучының йөкләмәсен ипотека белән тәэмин ителгән килешү буенча төзекләндерелгән торак урын сатып алуга түләүләр бирү өчен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

03 4 02 00000 «Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 05210 Хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05220 Тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05310 Реабилитацияләнгән затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга социаль ярдәм чараларын тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча реабилитацияләнгән затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга социаль ярдәм чараларын тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05510 Социаль ярдәмнең башка төрләрен күрсәтү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча социаль ярдәмнең башка төрләрен күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы

Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05520 Халыкка социаль ярдәм чараларын тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча халыкка социаль ярдәм чараларын тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05540 Җитмеш һәм сиксән яшькә җиткән ялгыз яшәүче эшләмәүче торак урын милекчеләренә торак урынны капиталь ремонтлауга кертем түләү чыгымнарын компенсацияләү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча җитмеш һәм сиксән яшькә җиткән ялгыз яшәүче эшләмәүче торак урын милекчеләренә торак урынны капиталь ремонтлауга кертем түләү чыгымнарын компенсацияләүне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 49100 Пенсияләргә өстәмә түләү, өстәмә пенсия белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча пенсияләргә өстәмә түләүләрне һәм өстәмә пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 49200 Татарстан Республикасы Конституция Судының отставкадагы судьяларына гомер буе ай саен түләү, эштән киткәндә пособие түләү, шулай ук матди һәм социаль тәэмин итүнең башка чараларын күрсәтү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы Конституция Судының отставкадагы судьяларына гомер буе ай саен түләүгә, эштән китү пособиесе түләүгә, шулай ук матди һәм социаль тәэмин итүнең башка чараларын күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- R4620 Аерым категорияләрендәге гражданнарга күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертемне түләүне компенсацияләүгә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча гражданнарның аерым категорияләренә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертемне түләүне компенсацияләүгә федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Гражданнарның аерым категорияләренә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертем түләүне компенсацияләүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25462 02 0000 150 керем төрләре коды буенча чагылдырыла.

03 4 03 00000 «Гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 05230 Җирләүгә социаль пособие түләү һәм җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча чыгымнарны каплау

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча мәет җирләүгә социаль пособие түләүне гамәлгә ашыруга һәм мәет җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05410 Социаль сәясәт өлкәсендәге чаралар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча чараларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла

- 05420 Социаль сәясәт өлкәсендә башка чаралар

- 05510 Социаль ярдәмнең башка төрләрен күрсәтү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча социаль ярдәмнең башка төрләрен күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05520 Халыкка социаль ярдәм чараларын тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча халыкка социаль ярдәм чараларын тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05530 Халыкның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча халыкның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05860 «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $8^2$ статьясында билгеләнгән аерым категориядәге гражданнарны торак белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $8^2$ статьясында билгеләнгән аерым категориядәге гражданнарны торак белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 25510 Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү өлешендә социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү өлешендә социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга җирле бюджетларга субвенцияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең җирле бюджетларга керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектларының тапшырыла торган вәкаләтләрен үтәүгә җирле бюджетларга субвенцияләр» 000 2 02 30024 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагыла.

Шулай ук чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча күрсәтелгән максатларга җирле бюджетларның чыгымнары чагылдырыла,

- 51340 «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән аерым категориядәге гражданнарны «1941 – 1945 елгы Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2008 елның 7 маендагы 714 номерлы Указы нигезендә федераль бюджет акчалары исәбеннән торак белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Бөек Ватан сугышы инвалидларын, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны,1941 елның 22 июненнән 1945 елның 3 сентябренә кадәрге чорда шул исәптән хәрәкәттәге армия составына кермәгән хәрби частьларда, учреждениеләрдә, хәрби-уку йортларында кимендә алты айлык хәрби хезмәт узган хәрби хезмәткәрләрне, шушы чорда хезмәт иткән өчен СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән хәрби хезмәткәрләрне; Бөек Ватан сугышы чорында һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, җирле һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, оборона корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм хәрәкәттәге фронтларның тыл чикләре, хәрәкәттәге флотларның операция зоналары чикләрендәге башка хәрби объектларда, тимер юл һәм автомобиль юлларының фронт яны участокларында эшләгән затларны, шулай ук Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләрнең портларында калган транспорт флоты суднолары экипажлары әгъзаларын; «Камалыштагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән затларны; һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның гаиләләре әгъзаларын, җирле һава һөҗүменә каршы оборонаның объектлар һәм аварияләр командаларының үзләрен саклау төркемнәренең шәхси составы арасыннан Бөек Ватан сугышында һәлак булган затларның гаиләләре әгъзаларын, шулай ук Ленинград шәһәре госпитальләре һәм хастаханәләренең һәлак булган хезмәткәрләренең гаиләләре әгъзаларын торак белән тәэмин итүгә федераль бюджет субвенцияләре исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «1941 – 1945 елгы Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2008 елның 7 маендагы 714 номерлы Указы нигезендә «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән аерым категориядәге гражданнарны торак белән тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бюджетларга

субвенцияләр» 000 2 02 35134 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

- 51350 «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән аерым категориядәге гражданнарны федераль бюджет акчалары исәбеннән торак белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча хәрби хәрәкәтләр инвалидларын, шулай ук хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт бурычларын) башкарганда яралану, контузияләнү яки гарипләнү сәбәпле инвалид калган эчке эшләр органнарының, янгынга каршы дәүләт хезмәтенең, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының хәрби хезмәткәрләрен һәм рядовой һәм җитәкчелек составына кергән затларын; хәрби хәрәкәтләр ветераннарын; хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт бурычларын) башкарганда һәлак булган эчке эшләр органнарының, янгынга каршы дәүләт хезмәтенең, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының һәм дәүләт иминлеге органнарының хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре әгъзаларын, рядовой һәм җитәкчелек составына кергән затларын, әсирлектә һәлак булган, хәрби хәрәктләр алып барылган урыннарда хәбәрсез югалган дип танылган хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларын торак белән тәэмин итүгә федераль бюджет субвенцияләре исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән аерым категориядәге гражданнарны торак белән тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бюджетларга субвенцияләр» 000 2 02 35135 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

- 51760 «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән аерым категориядәге гражданнарны федераль бюджет акчалары исәбеннән торак белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча хәрби хәрәкәтләр инвалидларын, шулай ук хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт бурычларын) үтәгәндә яралану. Контузияләнү яки гарипләнү аркасында инвалид калган эчке эшләр органнарының, янгынга каршы дәүләт хезмәтенең, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының хәрби хезмәткәрләрен һәм рядовой һәм җитәкчелек составына кергән затларын; инвалидларны һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында «1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән аерым категориядәге гражданнарны торак белән тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бюджетларга субвенцияләр» 000 2 02 35176 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

- 51980 Россия Федерациясенең Пенсия һәм социаль иминият фонды акчалары исәбеннән Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына социаль ярдәм

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды бюджетыннан Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән бюджетара трансфертлар исәбенә башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга бүтән бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына социаль ярдәм күрсәтүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45198 02 0000 150 керем төрләре коды буенча чагылдырыла.

- 52200 «Россиянең Мактаулы доноры» күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне федераль бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Россиянең Мактаулы доноры» күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне, банклар тарафыннан почта элемтәсе хезмәтләре һәм банк хезмәтләре өчен түләүне дә кертеп, гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтен хәл кылуга федераль бюджет субвенцияләре исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россиянең Мактаулы доноры» күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтен хәл кылуга бюджетларга субвенцияләр» 000 2 02 35220 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

- 52400 Вакцинадан соң өзлегүләр килеп чыкканда федераль бюджет акчалары исәбеннән гражданнарга бер мәртәбә бирелә торган дәүләт пособиеләре һәм айлык акчалата компенсацияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Йогышлы авыруларның иммунопрофилактикасы турында»1998 елның 17 сентябрендәге 157-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә вакцинадан соң өзлегүләр килеп чыкканда гражданнарга бер мәртәбә бирелә торган дәүләт пособиеләрен һәм айлык акчалата компенсацияләрне түләү буенча федераль бюджет субвенцияләре исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла..

Әлеге максатларга субвенцияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Йогышлы авыруларның иммунопрофилактикасы турында»1998 елның 17 сентябрендәге 157-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, вакцинадан соң өзлегүләр килеп чыкканда гражданнарга бер мәртәбә бирелә торган дәүләт пособиесен һәм айлык акчалата компенсация түләүгә бюджетларга

субвенцияләр» 000 2 02 35240 00 0000 150 к еремнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

- 52500 Аерым категориядәге гражданнарга торак-коммуналь хезмәтләр өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән түләү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Россия Федерациясе вәкаләтләренә карый торган затлар арасыннан аерым категория гражданнарга торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә, банклар тарафыннан почта элемтәсе хезмәтләре һәм банк хезмәтләре өчен түләүне кертеп, республика дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнарын да кертеп, шулай ук, үзләренә тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы (җирле администрацияләр) дәүләт хакимияте багшкарма органнарының һәм алар карамагындагы дәүләт (муниципаль) учреждениеләрнең чыгымнарын түләүгә федераль бюджет субвенцияләре исәбеннән хәл кылуга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Гражданнарның аерым категорияләренә торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә бюджетларга субвенцияләр" 000 2 02 35250 00 0000 150керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

- 52501 Гражданнарның аерым категорияләренә торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын тәэмин итү

- 52502 Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм алар карамагындагы учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнарын компенсацияләү

- 52520 Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды акчалары исәбеннән Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына һәм Дан орденының тулы кавалерларына социаль ярдәм

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды бюджетыннан Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына һәм Дан орденының тулы кавалерларына социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән бюджетара трансфертлар исәбенә башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга бүтән бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына һәм Дан орденының тулы кавалерларына социаль ярдәм күрсәтүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45252 02 0000 150 керем төрләре коды буенча чагыла.

03 4 04 00000 «Халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен һәм сыйфатны арттыру» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 02040 Үзәк аппарат

- 02950 Оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымы түләү

- 05010 Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат йортлар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларны тотуга һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05011 Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен дәүләт интернат-йортлары эшчәнлеген тәэмин итү

-05012 Картлар һәм инвалидлар өчен дәүләт интернат-йортларына матди-техник базаны камилләштерүгә, шул исәптән капиталь ремонт ясауга акча бирү

- 05014 Педагогик хезмәткәрләргә-картлар һәм инвалидлар өчен дәүләт интернат-йортларының яшь белгечләренә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары күрсәтү

- 05080 Халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрен тотуга һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05081 Халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү

- 05082 Дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренә матди-техник базаны камилләштерүгә, шул исәптән капиталь ремонт ясауга акчалар бирү

- 05083 Дәүләтнеке булмаган оешмаларда дәүләт социаль хезмәтләре күрсәтү

- 05084 Халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләренә –яшь белгечләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары күрсәтү

### 03 4 05 00000 «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында энергетика нәтиҗәсен арттыру һәм ягулык-энергетика ресурсларын куллануны оптимальләштерү» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 05010 Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йортлар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йортларны тотуга һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05015 Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен дәүләт интернат-йортларын яктырту системасын модернизацияләү

- 05016 Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен дәүләт интернат-йортларында сенсорлы краннар, басма краннар кертү

- 05017 Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен дәүләт интернат-йортларында хәрәкәт датчикларын кертү

- 05018 Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен дәүләт интернат-йортларында индукцион плитәләр һәм комплектлаучы детальләр кертү

- 05080 Халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрен тотуга һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 05085 Халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт учреждениеләренең яктырту системасын модернизацияләү

- 05086 Дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә сенсорлы краннар, басма краннар кертү

- 05087 Дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә хәрәкәт датчикларын кертү

- 05088 Дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә индукция плитәләрен һәм комплектлаучы детальләрне кертү

### 03 4 06 00000 «Инвалидларны реабилитацияләү һәм реабилитацияләү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- R5140 Инвалидларны реабилитацияләү һәм реабилитацияләү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча инвалидларны реабилитацияләү һәм абилитацияләү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруга федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары чараларын гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25514 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

## 2.4. «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы

«Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының максатчан статьяларына керә:

### 04 0 00 00000 «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасы

Әлеге максатчан статья буенча «Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.05.2023 № 655 карары нигезендә эшләнгән «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетының түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла торган чыгымнары чагылдырыла:

### 04 2 00 00000 Федераль (төбәк) проектлар

### 04 2 05 00000 «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча төбәк проектын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 21780 Төбәк проектында катнашучы яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирүне тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проектында катнашучы яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирүне тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- R4970 Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга финанслашуыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25497 00 0000 150 керемнәрнең тиешле төрләре кодлары буенча чагылдырыла.

04 2 06 00000 «Татарстан Республикасында ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак урыннары белән тәэмин итү» төбәк проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча төбәк проектын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 60820 Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, алар арасыннан булган затларга махсуслаштырылган торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннар бирүне тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга махсуслаштырылган торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннар бирүне тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- R0820 Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак урыннар белән тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 пункты нигезендә, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларны торак урыннар белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларны торак урыннар белән тәэмин итүгә

Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25082 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

04 2 07 00000 «Күпфатирлы йортларның техник торышын яхшырту» төбәк проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча төбәк проектын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 96010 Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча төбәк программа чараларын гамәлгә ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауның төбәк программасы чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

04 2 0К 00000 «Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» төбәк проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча төбәк проектын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 03610 «Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге өчен инженерлык һәм юл инфраструктурасы объектларын төзү» объектын булдыру

- 03611 «ВЭБ.РФ дәүләт үсеш корпорациясе акчалары исәбеннән «Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге өчен инженерлык һәм юл инфраструктурасы объектларын төзү " объектын булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясе акчалары исәбенә «Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге өчен инженерлык һәм юл инфраструктурасы объектларын төзү» объектын булдыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга акчаларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан кире кайтарылмый торган башка кертемнәр» 000 2 03 02099 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

- 03612 «Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге өчен инженерлык һәм юл инфраструктурасы объектларын төзү» объектын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге өчен инженерлык һәм юл инфраструктурасы объектларын төзү» объектын булдыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 03640 «Зеленодольск шәһәрендә урнашкан азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарларның универсаль склады» объекты өчен мәйданнан тыш челтәрләр» объектын булдыру

- 03641 «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясе акчалары исәбеннән «Зеленодольск шәһәрендә урнашкан азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарларның универсаль склады» объекты өчен мәйданнан тыш челтәрләр» объектын булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясе акчалары исәбенә Татарстан Республикасы бюджетының «Зеленодольск шәһәрендә урнашкан азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарларның универсаль складады» объекты өчен мәйданнан тыш челтәрләр» объектын булдыруга тотыла торган татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга акчаларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан кире кайтарылмый торган башка кертемнәр» 000 2 03 02099 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

- 03642 « Зеленодольск шәһәрендә урнашкан азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарларның универсаль склады» объекты өчен мәйданнан тыш челтәрләр» объектын  Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Зеленодольск шәһәрендә урнашкан азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарларның универсаль склады» объекты өчен мәйданнан тыш челтәрләр» объектын булдыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 03650 «Менделеевск 2.0 «муниципаль сәнәгать паркының инженерлык инфраструктурасын төзү» (1 чират)» объектын булдыру

- 03651 «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясе акчалары исәбеннән «Менделеевск 2.0» (1 чират)» муниципаль сәнәгать паркының инженерлык инфраструктурасын төзү объектын булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Менделеевск 2.0» муниципаль сәнәгать паркының инженерлык инфраструктурасын төзү (1 чират)» объектын булдыруга «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясе акчалары исәбенә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга акчаларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан кире кайтарылмый торган

башка кертемнәр» 000 2 03 02099 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

- 03652 «Менделеевск 2.0» муниципаль сәнәгать паркының инженерлык инфраструктурасын төзү (1 чират)» объектын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән төзү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Менделеевск 2.0» муниципаль сәнәгать паркының инженерлык инфраструктурасын төзү (1 чират)» объектын булдыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 09500 Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыруга Территорияләрне үстерү фондыннан кергән акчалар исәбеннән башкарыла торган чыгымнар

- 09505 Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын Территорияләрне үстерү фонды акчалары исәбеннән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын тәэмин итүгә «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга акчаларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын тәэмин итүгә «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясеннән Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кире кайтарылмый торган кертемнәр» 000 2 03 02080 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

- 09600 Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнар

- 09605 Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 72310 Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкендәге социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт.

04 2 И3 00000 «Коммуналь инфраструктураны модернизацияләү»
федераль проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча федераль проектны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 51540 Коммуналь инфраструктураны модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча коммуналь инфраструктураны модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка субсидияләр» 000 2 02 29999 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

04 4 00 00000 процесс чаралары комплекслары

04 4 01 00000 «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы эшчәнлеген тәэмин итү һәм архитектура, шәһәр төзелеше, гражданлык һәм сәнәгать төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 02040 Үзәк аппарат

- 02950 Оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымы түләү

- 05850 Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 14150 Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә чаралар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 14200 «Татарстан Республикасының иң төзек торак пункты» исеменә республика конкурсында җиңүчеләрне бүләкләү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Татарстан Республикасының иң төзек торак пункты» исеменә республика конкурсында җиңүчеләрне бүләкләүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 72370 «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә һәр бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага субсидияләр

- 92990 Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итү

04 4 02 00000 «Төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) хәл итү»
процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 02040 Үзәк аппарат

- 02950 Оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымы түләү

- 92990 Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итү

04 4 03 00000 «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге
инспекциясе эшчәнлеген тәэмин итү» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 02040 Үзәк аппарат

- 02950 Оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымы түләү

- 92350 Башка түләүләр

- 92990 Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итү

2.5. «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм»
Татарстан Республикасы дәүләт программасы

«Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасының максатчан статьялары үз эченә ала:

05 0 00 00000 «Татарстан Республикасы халкын эш белән
тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасы

Әлеге максатчан статья буенча «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» 30.05.2023 № 655 карары нигезендә эшләнгән Татарстан Республикасы бюджетының түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла торган чыгымнары чагылдырыла:

05 2 00 00000 Федераль (төбәк) проектлар

05 2 Л1 00000 «Хезмәт базары белән идарә итү» федераль проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча федераль проектны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 52910 Мәшгульлек хезмәтенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча мәшгульлек хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Мәшгульлек хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25291 00 0000 150 керем төренең тиешле коды буенча чагылдырыла.

05 2 Л2 00000 «Хезмәт базары өчен мәгариф» федераль проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча федераль проектны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 52920 Оборона-сәнәгать комплексы оешмалары хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча оборона-сәнәгать комплексы оешмалары хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыруга федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Оборона-сәнәгать комплексы оешмалары хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр" 000 2 02 25292 02 0000 150 керем төрләре коды буенча чагылдырыла.

05 2 Л4 00000 «Хезмәт кешесе» федераль проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча федераль проектны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 55700 «Һөнәре буенча иң яхшысы» Бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының федераль этапларын оештыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Һөнәре буенча иң яхшысы» Бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының федераль этапларын оештыруга федераль бюджет субсидияләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Һөнәре буенча иң яхшысы» Бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының федераль этапларын оештыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25570 02 0000 150 керем төрләре коды буенча чагылдырыла.

05 4 00 00000 Процесс чаралары комплекслары

05 4 01 00000 «Халыкны эш белән тәэмин итүнең актив сәясәте һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм» процесс чаралары комплексы

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 15150 Кече эшмәкәрлекне һәм эшсез гражданнарның үзмәшгульлеген үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча кече эшмәкәрлекне һәм эшсез гражданнарның үзмәшгульлеген үстерүгә ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 15220 Эшсез гражданнарны, 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эш белән тәэмин итүне оештыру буенча чара

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча эшсез гражданнарны, 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эш белән тәэмин итүне оештыру чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 15240 Эш бирүчеләргә инвалидлар өчен эш урыннарын саклап калу һәм булдыруга субсидияләр бирү

